Югары белем бирүче федераль  дәүләт үзидарәле мәгариф учреждениесе
″Казан (Идел буе) федераль университеты″ның
Алабуга институты

# ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ ЭШЛӘРЕН ЯЗУ МЕТОДИКАСЫ

АЛАБУГА
2014

Казан федераль университетының Алабуга институтының редакция-нәшрият советы карары белән басыла

УДК 378:001.891

ББК 74.58

Ә 95

Бәяләүчеләр:

Ф.Г. Галләмов – филология фәннәре докторы, профессор;

Ф.Г. Даутов – филология фәннәре кандидаты, доцент.

Әхмәдгалиева Г.Г. Фәнни-тикшеренү эшләрен язу методикасы. – Алабуга: КФУ АИ нәшрияты, 2014. – 37 б.

Әлеге методик кулланма татар һәм чагыштырма филология факультеты студентларына курс һәм чыгарылыш квалификация эшләрен дөрес һәм бу төр эшләргә куелган таләпләргә туры китереп язу өчен тәкъдим ителә.

© Әхмәдгалиева Г.Г., 2014.
© КФУ АИ нәшрияты, 2014.

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ…....................................................................................................................
I. КУРСҺӘМ ЧЫГАРЫЛЫШ КВАЛИФИКАЦИЯ ЭШЛӘРЕН ЯЗУНЫ ОЕШТЫРУ
1.1. Фәнни-тикшеренү эшләренең максаты…......................................
1.2. Фәнни эшләрнең эчтәлегенә куела торган таләпләр…............................
1.3. Тема сайлау…....................................................................................................
1.4. Фәнни җитәкчелек…..............................................................
1.5. Курс һәм чыгарылыш квалификация эшен язуның календарь планы….....
1.6. Фактик материал туплау….................................................
II. КУРС ҺӘМ ЧЫГАРЫЛЫШ КВАЛИФИКАЦИЯ ЭШЛӘРЕН ОЕШТЫРУ БУЕНЧА МЕТОДИК КИҢӘШЛӘР
2.1. Титул бите.........................
2.2. Эчтәлек...........................
2.3. Кереш..........................
2.4. Төп өлеш....................
2.5. Йомгак.......................
2.6. Библиография...........................
2.7. Кушымта..........................................
III. КУРС ҺӘМ ЧЫГАРЫЛЫШ КВАЛИФИКАЦИЯ ЭШЛӘРЕНДӘ МАТЕРИАЛЛАРНЫҢ БИРЕЛЕШЕНӘ ТАЛӘПЛӘР............................
3.1. Гомумми таләпләр................
3.2. Сылтамалар яки астөшермәләр бирелеше.......................
3.3. Таблицалар............
3.4. Рәсемнәр.....
3.5. Кушымталар.....
3.6. Библиография.....
IV. КУРС ҺӘМ ЧЫГАРЫЛЫШ КВАЛИФИКАЦИЯ ЭШЛӘРЕН ЯКЛАУ....
4.1. Курс яки чыгарылыш квалификация эшен яклауга әзерлек…..................
4.2. Курс яки чыгарылыш квалификация эшен яклау…...............................
КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ……………………………..
КУШЫМТАЛАР……………………………………..

# КЕРЕШ

Курс эшләре һәм чыгарылыш квалификация эшләре татар һәм чагыштырма филология факультетында уку процессының мөһим өлеше булып тора. Аларны язу вакытында студентлар татар теле һәм әдәбияты буенча, аларның төрле тармаклары, мәсьәләләре буенча үзләренең белемнәрен тирәнәйтү өчен тикшеренү эшләрен мөстәкыйль алып барырга, фәнни эшләр язуның беренче тәҗрибәсе булырга тиеш. Уку планы нигезендә «Туган тел һәм әдәбият, чит тел» профиле буенча укучы студентлар III курсның 6 семестрында татар теле буенча, ә IV курсның 8 семестрында – инглиз теле буенча курс эше язарга тиешләр. V курс ахырында бар студентлар да чыгарылыш квалификация эшен язып, аны якларга тиеш булалар – бу чыгарылыш дәүләт имтиханнарының бер өлеше булып тора. Шулай итеп, чыгарылыш квалификация эшен язу һәм яклау югары һөнәри белем бирүнең соңгы этабын тәшкил итә. Чыгарылыш квалификация эше студентның сайланган белгечлеге буенча һөнәри әзерлек дәрәҗәсен билгеләү максатыннан чыгып яздырыла.

Бу төр эшләргә тотынганда, студент алдына бик күп төрле сораулар килеп баса: эшне нидән башларга, нәрсәләргә күбрәк игътибар итәргә, библиографияне ничек төзергә, астөшермәләрне ничек бирергә, титул бите ничек язылырга, фәнни эшнең төзелеше нинди булырга тиеш, фактик материалны ничек тупларга һ.б. Бу методик кулланма әлеге сорауларга җавап бирүне күздә тотып төзелде.

Тәкъдим ителә торган методик кулланмабыз фәнни җитәкчеләр өчен дә файдалы булыр дип уйлыйбыз, чөнки төрле җитәкчелектә язылган эшләрдә аны формалаштыруда төрлелек күзәтелә.

# I. КУРС ҺӘМ ЧЫГАРЫЛЫШ КВАЛИФИКАЦИЯ ЭШЛӘРЕН ЯЗУНЫ ОЕШТЫРУ

## 1.1. Курс һәм чыгарылыш квалификация эшләренең максаты.

Курс һәм чыгарылыш квалификация эшләренең максаты – фәнни эш язу методикасын үзләштерү, чыганак һәм фәнни әдәбият белән эшләү тәҗрибәсен, үзенең тикшеренү эшенең нәтиҗәләрен тәкъдим итү күнекмәләрен булдыру.

Студентлар тарафыннан язылган эшләргә куела торган таләпләр:

- сайлап алынган теманың актуаль һәм моңарчы тикшерелмәгән (аз тикшерелгән) булуы;
- тикшеренү эшенең студент тарафыннан мөстәкыйль башкарылуы;
- эшнең логик эзлеклелектә булуы һәм фикерләрнең, фактларның мисаллар белән дәлилләнеп килүе;
- чыганакларның һәм фәнни әдәбиятның комплекслы анализы;
- нәтиҗәләр конкрет һәм дәлилләнгән булуы (параграф яисә бүлек ахырында иң кыйммәтле фикерләрне туплап, берничә җөмлә белән йомгаклап кую);
- фәнни эштә махсус терминологиянең кулланылышы;
- эшнең язылышы техник һәм методик яктан бу төр эшләргә куела торган таләпләргә туры килергә тиеш.

## 1.2. Фәнни эшләрнең эчтәлегенә куела торган таләпләр

III курста языла торган курс эше татар филологиясенең берәр фәнни мәсьәләсе («Туган тел һәм әдәбият, чит тел» профиле) яки тарих буенча («Туган тел һәм әдәбият, тарих» профиле) тикшерү эше алып баруны күз алдында тота. Эшне язган вакытта студент чыганаклар белән, фәнни әдәбиятны барлау белән библиографик исемлек төзү, мәсьәләнең өйрәнелү тарихын тикшерү кебек эшләр башкара. Шулай ук мөһим мәгълүматны аерып чыгару, материалны эзлекле рәвештә бирү, бу мәсьәләгә үзенең карашын белдерү, фәнни нәтиҗәләргә аңлатмалар бирү кебек эшләрне

башкарырга өйрәнә.

III курста фәнни эшнең (курс эшенең) күләме 25 басма биттән ким булмаска тиеш (эшнең күләменә кушымта кертелми).

IV курста «Туган тел һәм әдәбият, чит тел» профиле буенча укучы студентлар инглиз яки төрек теленнән, «Туган тел һәм әдәбият, тарих» профиле буенча укучы студентлар татар әдәбиятыннан курс эшләре язалар. IV курста тикшерелә торган темага киң фактик материал һәм аның җентекле анализы китерелергә тиеш. Күләме басма тексттан торган 30 биттән дә ким булмаска тиеш (кушымтаны кертмичә).

Чыгарылыш квалификация эше дигәндә, сайлап алынган тема буенча һәръяклап тикшерелгән, төгәлләнгән эшне күз алдында тоталар. ЧКЭны язганда фәнни эшләргә куела торган бар таләпләр дә үтәлергә тиеш:

1) күтәрелгән мәсьәләнең тикшерелмәгән булуы (яңалыгы);

2) студентның бәхәсле урыннарда үз фикерен дәлилли, исбат итә белүе;

3) фәнни эшнең нәтиҗәләре расланган булуы;

4) ЧКЭдә мөстәкыйль рәвештә тупланган материалның китерелүе;

5) ЧКЭнең күләме 50 басма битлек тексттан ким булмаска тиеш (кушымта һәм библиографияне кертмичә).

## 1.3. Тема сайлау.

Фәнни эшләр өчен темаларны кафедра укытучылары тәкъдим итә. Ул темалар башта кафедра утырышында карала, аларның актуальлек дәрәҗәсе, яңалыгы һәм теоретик әһәмияте тикшерелә. Темалар, гадәттә, кафедра галимнәренең фәнни-тикшеренү эшләренә, юнәлешенә нигезләнеп биреләләр.

Укытучылар тәкъдим иткән темаларның берсен студент үзе сайлап ала һәм җитәкче укытучыга хәбәр итә. Әгәр темалар исемлегеннән студент үзенә ошаган тема сайлап ала алмаса, ул үзенең темасын да тәкъдим итә ала. Мөмкин булса, бу студентның курс эшенең киңәйтелгән темасы булырга (V курс студентлары өчен), яисә фәнни түгәрәктә тикшерелгән темасы була ала.

Фәнни җитәкче белән бер фикергә килгәч, фәнни эшне язуның алдагы этабына күчәләр. Фәнни эшләрне язган вакытта үзеңә якын булган, бу юнәлештә фәнни әдәбият булган темаларның берсен сайларга тырышырга кирәк.

V курсның 9 семестры башында, ягъни сентябрь аенда тәкъдим ителгән чыгарылыш квалификация эшләре темалары сайланып беткәннән соң, бу темалар факультет Советында яңадан тикшерелә, раслана һәм моның хакында боерык чыгарыла. Анда ЧКЭ темасы, студентның фамилиясе һәм җитәкчесе күрсәтелә. Боерык чыкканнан соң, теманы, җитәкчене үзгәртү, алыштыру рөхсәт ителми. Бары тик эш бик авыр барган очракта гына, искәрмә рәвешендә, яңа карар чыгарып, теманы алыштырырга яисә башка үзгәрешләр кертергә мөмкин.

## 1.5. Фәнни җитәкчелек.

Курс һәм чыгарылыш квалификация эшләренең язылышы белән татар филологиясе кафедрасы профессорлары, доцентлары, өлкән укытучылары җитәкчелек итә ала. Студентларның фәнни җитәкчене үзләре сайлап алу мөмкинлеге бар. Октябрь аена кадәр бу эш төгәлләнергә тиеш (V курслар өчен). Әгәр студент бер мөгаллимгә дә язылмаса, кафедра карары белән, ул берәр җитәкчегә беркетелә.

Кафедра утырышында студентлар һәм аларның җитәкчеләре, фәнни-тикшеренү эшенең темасы язылган исемлек тикшерелә һәм раслана.

Җитәкче тикшеренү эшен язу дәвамында киңәшләрен, тәкъдимнәрен әйтә, эшнең барышын контрольдә тота, тик әзер нәтиҗәләр, әзер материаллар бирми. Җитәкче яклауга чыгарыла торган фәнни-тикшеренү эшенең сыйфаты өчен җаваплы, дәүләт аттестацияләү комиссиясе (ДАК) алдында яклана торган чыгарылыш квалификация эшенә үз бәяләмәсен дә яза.

*Фәнни җитәкче белән студентның хокук һәм бурычлары*

Курс яки чыгарылыш квалификация эшен язу процессында ике генә кеше катнаша: фәнни җитәкче һәм хезмәтне язучы студент. Аларның үз

хокуклары һәм бурычлары бар.

Фәнни җитәкче бурычлы:

- курс яки чыгарылыш квалификация эше өстендә эшләү өчен студентка биремнәр бирергә, аның үтәлү срогын билгеләргә;
- кафедрада расланган график буенча консультацияләр үткәрергә;
- тема буенча төп әдәбият тәкъдим итәргә, студент белән берлектә өйрәнү объектын һәм предметын, максат һәм бурычларны билгеләргә, төп өлешкә караган фактик материалны эшкәртүдә, нәтиҗәләр чыгаруда ярдәм итәргә;
- курс яки чыгарылыш квалификация эшенә куела торган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;
- курс яки чыгарылыш квалификация эше язуның төрле этапларында язылган текст белән танышырга, студент тарафыннан башкарылган эшләрне контрольдә тотарга;
- курс яки чыгарылыш квалификация эшенең куелган таләпләргә җавап бирүе турында яклауга кадәр бәяләмә язарга, рецензентка эшнең вакытында бирелүен контрольдә тотарга.

Фәнни җитәкче хокуклы:

- студент аның күрсәтмәләрен кире какса, эш графигын үтәмәсә, курс яки чыгарылыш квалификация эше белән җитәкчелек итүдән баш тартырга;
- чыгарылыш квалификация эшенә язылган бәяләмәсендә студент төзәтергә теләмәгән кимчелекләрне күрсәтергә;
- студент чыгарылыш квалификация эшенә куела торган таләпләрне үтәмәсә, эшне яклауга тәкъдим итмәскә.

Студент бурычлы:

- җитәкче төзегән график буенча консультацияләргә йөрергә;
- курс һәм чыгарылыш квалификация эшен язу һәм яклау графигын үтәргә;
- эшне язу процессында туган барлык кыенлыклар турында фәнни җитәкчегә хәбәр итәргә;
- фәнни җитәкченең чыгарылыш квалификация эшен язуга кагылышлы бөтен таләпләрен төгәл үтәргә.

Студент хокуклы:

- курс яки чыгарылыш квалификация эше язуның беренче этабында, җитәкче белән килешеп, теманы бераз үзгәртергә яисә төзәтмә кертергә;
- төп сәбәбен дәлилләп, фәнни җитәкчене алыштыру өчен, кафедра мөдиренә мөрәҗәгать итәргә;
- фәнни җитәкче һәм рецензентның фикере белән туры килмәсә дә, үз фикерен дәлилләп, аны нигезләп, якларга.

1.5. Чыгарылыш квалификация эшен язуның календарь планы.

Факультет Советында темалар раслангач, фәнни җитәкче белән берлектә фәнни эшне язуның календарь планы төзелә. Анда түбәндәгеләр чагылыш табарга тиеш:

1) өйрәнелә торган тема буенча фәнни әдәбият җыю, аның белән танышу;
2) теманың өйрәнелү дәрәҗәсен билгеләү;
3) булган проблемаларны ассызыклап күрсәтү, хезмәтнең структурасын ачыклау, алга куелган гипотезаларны нигезләү;
4) фактик материал туплау, аны төркемләү һәм анализлау;
5) фәнни эшнең текстын, эчтәлегенә, структурасына туры китереп язу;
6) текстка төзәтмәләр кертү;
7) эшне тиешле таләпләргә туры китереп, фәнни җитәкчегә тикшерергә тапшыру;
8) фәнни җитәкченең киңәшләрен һәм күрсәтмәләрен үтәп, тикшерenү эшенә төзәтмәләр кертү;
9) эшне бәяләр өчен рецензентка тапшыру һәм кимчелекләр белән танышу;
10) фәнни эшне якларга әзерлек.

Фәнни җитәкче консультацияләрнең көннәрен һәм сәгатьләрен билгели. Эш процессында туган сораулары белән студент билгеләнгән вакытларда консультацияләргә килергә тиеш.

Теманы ачыклаганнан соң, чыганаклар һәм фәнни әдәбият исемлеген төзеп, аның белән танышырга кирәк. Эш барышында, фәнни җитәкче тәкъдим иткән әдәбият белән генә чикләнмичә, башка хезмәтләр белән дә

танышырга кирәк. Моның өчен вузның, шәһәр, район китапханәләрендә күп кенә материаллар белән эш итәргә кирәк. Кайчакта вакытлы матбугатта басылып чыккан мәкаләләр, очерклар да ярдәм итәргә мөмкин. Тупланган әдәбият исемлеге фәнни җитәкчегә күрсәтелә, андагы мәгълүмат ни дәрәҗәдә темага туры килүе, файдалы булуына игътибар ителә.

Эш планы теманың, аның эчтәлеген тулысынча ачарга тиеш. Фәнни материалны туплаганда, әлеге материал кайдан алынган, тулы библиографик тасвирламасы белән теркәлеп барылырга тиеш. Болай эшләгәндә, кереш өлешендә чыганакларга анализ ясаганда, астөшермәләрне күрсәткәндә, чыганак һәм кулланылган әдәбият исемлеген төзегәндә күп кенә мәшәкатьләрдән азат итәчәк.

Фәнни эшне язган вакытта студент теге яки бу тел, яисә әдәби күренешләргә, материалга карата мөстәкыйль рәвештә үзенең мөнәсәбәтен белдерергә, мөмкин булган кадәр чит фикерләрне, карашларны аз кулланырга тиеш. Һәр фикер, һәр гипотеза чыганаклар һәм астөшермәләр белән бирелгән әдәбият исемлегенә ишарә ясарга тиеш. Сүзгә сүз кулланылган материал цитата буларак һәм куштырнакларда бирелеп барса, эшнең кыйммәте артачак. Эшне бәян итү логик эзлеклелектә, күплек сандагы беренче зат тарафыннан булырга тиеш. Мәсәлән, *безнең тарафтан тикшерелде, безнең карашка, безнең уйлавыбызча* һ.б. Шулай ук табылган материал арасында сәбәп-максат элемтәләре дә булырга тиеш.

Фәнни эшнең кереш һәм йомгак өлешләре, кагыйдә буларак, төп өлеш язылып беткәннән соң языла, чөнки кереш өлешендә файдаланылган әдәбиятка күзәтү, чыганакларга, фәнни әдәбиятка анализ, характеристика ясала. Эшнең максаты һәм бурычлары билгеләнә, методологик нигезе күрсәтелә, ә йомгакта тулаем бер эшнең нәтиҗәләре китерелә.

Бу өлешләр өстендә эшләгәндә, аеруча III курс студентларына, җитәкченең ярдәме кирәк, чөнки формулировкаларның төгәл һәм фәнни булуы, төп текстка туры килүе таләп ителә. Каралама вариантны, җитәкче тикшергәннән соң, чиста һәм соңгы вариантны ясарга рөхсәт ителә.

## 1.5. Фәнни әдәбият белән танышу

Тема алганнан соң фәнни әдәбият белән җентекләп танышып чыгу сорала. Бу мәсьәләдә фәнни җитәкче юнәлеш бирергә тиеш, ләкин студент җитәкче биргән хезмәтләрне өйрәнү белән генә чикләнергә тиеш түгел. Ул үзе дә фәнни, методик журналлардан теоретик материаллар туплый. Мәсәлән, татар теленнән фәнни эш язганда «Мәгариф», «Фән һәм мәктәп», «Вопросы языкознания» һ.б. журналларда басылып чыккан мәкаләләр, текстлар белән танышу фәнни эшне язганда зур ярдәм итәчәк һәм библиографияне шактый тулыландырачак. ЧКЭ язганда, татар филологиясе белән генә чикләнмичә, бу мәсьәләгә карата башка телләрдә нинди фикерләр, карашлар булуына игътибар итү сорала.

Тема буенча фәнни әдәбиятны барлау өчен, библиографик күрсәткечләр ярдәм итәчәк. Мәсәлән, татар теленнән фәнни-тикшеренү эше язу өчен, төрле чорларны үз эченә алган түбәндәге библиографик күрсәткечләрне тәкъдим итәргә мөмкин:

Якупова Г.К. Библиография по татарскому языкознанию (1778-1980). – Казань: Тат.книжное изд-во, 1983.

Хәкимҗан Ф.С., Хәйретдинова Г.Х. Татар тел белеме библиографиясе (1981-1997). – Казан, 1998.

Татар әдәбиятыннан язучыларга:

1. Кәримуллин Ә.Г. Татар әдәбияты (Фольклор, әдәбият белеме һәм әдәбият тарихы). Библиография. 1917-1959. – Казан, 1961.

2. Әдәбият баскычлары. Татар совет әдәбияты елъязмасы (1917-1973). – Казан, 1976.

3. Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары. Библиографик белешмә. – Казан, 1986.

## 1.6. Фактик материал туплау.

Җитәрлек күләмдә фәнни әдәбият белән танышып, бу теманы нindирәк аспекта тикшерергә икәнлеге һәм чыгарылыш квалификация эшендә нинди

методлар һәм алымнар куллану кирәклеге ачыклангannan соң, студент тикшерелә торган мәсьәләгә караган фактик материал туплау эшенә тотына. Татар теленнән фәнни-тикшеренү эше башкарганда, гадәттә, стандарт карточкалар ясарга туры килә. Һәр карточкага үзенең темасына туры килә торган бер генә тел факты теркәлгән мисал языла. Әгәр ул җөмлә рәвешендә язып алынган булса, дәлил булып хезмәт иткән өлеше аерылып күрсәтелә. Җыелган материал җитәрлек күләмдә туплангач, аны максатка ярашлы итеп, системага китереп, төркемлиләр. Бер төркемгә караган тел фактларының бөтен үзенчәлекләрен дә тикшереп, аерым бүлек яисә параграф итеп бирергә мөмкин, анда әлеге тел фактлары буенча ачыкланган нәтиҗәләрне урнаштыралар.

## II. КУРС ҺӘМ ЧЫГАРЫЛЫШ КВАЛИФИКАЦИЯ ЭШЛӘРЕН ОЕШТЫРУ БУЕНЧА МЕТОДИК КИҢӘШЛӘР

Курс һәм чыгарылыш квалификация эшләре гадәттә түбәндәге өлешләрдән тора:

- титул бите;
- эчтәлек (титул бите һәм эчтәлектә бит саны күрсәтелми);
- кереш (3 биттән башлана);
- төп өлеш (ул берничә бүлектән тора, һәр бүлек параграфларга бүленә). Эчтәлектә һәм текста *төп өлеш* сүзе язылмый, бары бүлек исеме генә языла;
- йомгак;
- библиография;
- кушымта;
- шартлы кыскартылмалар исемлеге.

### 2.1. Титул бите.

Курс эше һәм ЧКЭның *титул бите*ндә иң өстә, федераль министрлык, аннары федераль белем бирү оешмасы, югары уку йорты һәм факультет, фәнни эш башкарыла торган кафедра исемлеге күрсәтелә. Бераз ара калдырып, эшнең төре (реферат, курс эше, ЧКЭ), аннан соң эшнең исеме языла. *Тема* сүзе язылмый, атама куштырнаклар эчендә бирелми, болар барысы да битнең уртасында күрсәтелә.

Алардан соң битнең сул өлешендә *фәнни эшне башкарды, фәнни эшне тикшерде, фәнни эш яклауга әзер* кебек сүзләр языла. Уң яктан студентның, аның җитәкчесенең, кафедра мөдиренең фамилиясе һәм инициаллары языла. Бит ахырында эшне башкарган торак пунктының исеме һәм елы күрсәтелә (Титул битләренең үрнәге 2 КУШЫМТАда китерелә).

### 2.2. Эчтәлек.

Эчтәлек титул битеннән соң бирелә. Анда фәнни эшнең төзелеш

структурасы чагылыш таба. Теге яки бу өлешнең, бүлек һәм параграфларның кайсы биттән башлануы күрсәтелә.

Текст эчендәге бүлек һәм параграфларның исеме эчтәлектәге атамаларга һәм анда күрсәтелгән битләргә туры килергә тиеш. Кереш, бүлек исемнәре, йомгак, библиография, кушымталар, текста яңа биттән башлап языла. Ә параграф исемнәре өчен бу мәҗбүри түгел.

Төп бүлекләрнең исеме (КЕРЕШ, бүлек атамалары, ЙОМГАК, БИБЛИОГРАФИЯ, КУШЫМТА) тоташтан баш хәрефләрдән языла. Параграф атамалары кызыл юлдан, баш хәрефтән башланып, калганнары юл хәрефләре белән дәвам иттерелә.

## 2.3. Кереш.

Кереш – теләсә нинди фәнни-тикшеренү эшенең мөһим һәм җаваплы өлеше булып санала. Ул эш белән танышучыны алда китереләчәк мәгълүмат белән танышуга әзерли, кирәкле квалификацион тикшеренү характеристикаларын үз эченә ала. Кереш бер төрле «визит карточкасы» функциясен үти, башка тикшеренүчеләр өчен тәкъдим ителә торган эшнең кыйммәтен һәм мөһимлеген күрсәтә.

Студентлар тарафыннан башкарылган фәнни эшләрнең кереш өлешенең күләме 4-6 бит булырга мөмкин. Монда теманың актуальлеге, аны ни өчен сайлау нигезләнә, максат һәм бурычлар билгеләнә, өйрәнү объекты һәм предметы ачыклана, тикшеренү методлары һәм алымнары турында әйтелә. Теманың өйрәнелү дәрәҗәсе, теоретик һәм гамәли әһәмияте билгеләнә. Эшне язган вакытта төп таяныч булган фактик материаллар, чыганаклар күрсәтелә. Төзелеше хакында кыскача языла, әгәр апробация үткән булса, бу турыда да искәртелә.

Керештә таблицалар, график, схемалар һ.б.ш. китерелми.

*Фәнни эшнең актуальлеге* хәзерге заман өчен тикшерелә торган күренешнең, процессның мөһимлеге, заманча фикерләүнең бу мәсьәләгә мөнәсәбәте-бәяләмәсе күрсәтелә, ягъни эшнең актуальлеге дигәндә,

тикшерелә торган мәсьәлә ничек, ни рәвешле бүгенге көн мәдәни, иҗтимагый-сәяси, бәлки икъдисади процесслар белән кисешүе яисә бәйләнештә торуын күрсәтү була. Эшнең актуальлеге берничә абзацтан башлап бер биткә кадәр була.

Төрле өлкәләрдә язылган теләсә нинди фәнни эшнең мөһим өлеше булып аның *объектын һәм предметын билгеләү* тора. Аларны билгеләү һәрвакыт билгеле бер кыенлык һәм күп сораулар тудыра. Объект – процесс яки күренешне өйрәнү, тикшерү өчен проблемалы ситуация барлыкка китерә торган җирлек. Предмет – ул объект чикләрендә булган материал.

*Методологик нигез* – фәнни эшне язган вакытта конкрет методлар һәм чараларны куллануны күз алдында тота:

1) типиклаштыру (метод типизации) – бик күп төрле билгеләр арасыннан охшаш һәм төрле булган билгеләрне, аларны берләштерә торган бер модельгә яисә типка туплау;

2) сайлап алу методы (выборочный метод) – гадәттә бу метод киң теоретик материал булмаган очракта, өйрәнелә, тикшерелә торган күренешләрне тагы да җентекле рәвештә, төгәлрәк тикшеренүләр үткәрер өчен кулланыла. Бу метод күренешнең кайбер якларын гына тикшереп, башка күренешләр турында нәтиҗәләр ясарга ярдәм итә;

3) чагыштыру методы (сопоставительный метод) – төрле телләрдәге охшаш күренешләр, вакыйгалар, мәсьәләләр чагыштырылып тикшерелә. Бу метод ярдәмендә күренешләр арасында бәйләнешне, фактик материалның охшаш һәм аерымлыкларын күрсәтергә ярдәм итә;

4) статистик (санау) методы. Бу метод ярдәмендә теге яисә бу күренешнең кулланылу ешлыгы, дәрәҗәсе статистик санау ярдәмендә күрсәтелә. Нәтиҗәләр төрле диаграммалар, схемалар, графиклар, таблицалар ярдәмендә күрсәтелә. Бу нәтиҗәләр охшаш күренешләр белән чагыштырырга мөмкинлек бирә.

*Фәнни яңалык* дип күтәрелгән мәсьәләнең беренче мәртәбә яктыртылуы, җентекләп өйрәнелүе, нәтиҗәләрнең яңа гына ачыклануы һәм

әлеге материалларның моңарчы беркайда да яктыртылмавы исәпләнә.

Фәнни яңалыкны табу бик авыр, ләкин шул ук вакытта гомуми планда бирелгән берәр хезмәтнең аз яктыртылган өлешен җентекләп өйрәнү фәнни эшнең яңалыгы булып санала ала. Шулай ук фәнни яңалык булып тикшерелгән мәсьәләгә яңача караш белән, яңа методлар кулланып, әлеге мәсьәләне яктырту да исәпләнелә.

*Эшнең практик кыйммәте* – фәнни эшнең төп положениеларының практикада, ягъни гамәлдә куллана алу мөмкинлеге дигәнне аңлата һәм кайда, ни рәвешле кулланыла алуына ишарә ясый.

## 2.4. Төп өлеш.

Төп өлешнең бүлекләрендә логик эзлеклелектә бик җентекләп, фактлар һәм аргументлар китерелеп, тикшеренү материаллары бирелә. Барлык материаллар күләме буенча эшнең 2/3 өлешен тәшкил итәргә тиеш. Кагыйдә буларак, төп өлеш берничә бүлектән (2-3), ә алар үз чиратында 2-6 кадәр параграфларга бүленә. Һәрбер бүлек нинди да булса максатка юнәлдерелгән була. Алдагысы шуннан соң килгән бүлеккә нигез булырга тиеш, ягъни куелган проблемаларның теоретик анализы була. Шуннан соң килгән бүлектә фактик материалны эксперименталь тикшерү яисә фәнни анализ нәтиҗәләре турында языла: текста таблицалар, графиклар, диаграммалар һ.б. китерелергә мөмкин. Һәрбер бүлектән соң кыскача нәтиҗәләр китерелә.

Төп бүлекне язган вакытта, түбәндәге тәкъдимнәрне истә тотарга кирәк:

1) бүлекләр һәм параграфлар исемнәре аларның эчтәлеген чагылдырырга тиеш: төгәл, конкрет, азсүзле булырга һәм ике мәгънәле булмаска тиеш;

2) һәрбер бүлекне, мөстәкыйль эчтәлеккә ия булган өлеш буларак, нәтиҗәләр төгәлләргә тиеш. Бу нәтиҗәләр китерелгән материалларны гомумиләштерергә һәм алдагы бүлеккә логик күчеш формасында булырга тиеш;

3) бүлек азагында китерелгән нәтиҗәләр тикшеренү этаплары буенча гомуми нәтиҗәләр чыгарырга ярдәм итәргә тиеш.

## 2.5. Йомгак.

Йомгакта тикшеренү эшләренең төп нәтиҗәләре чыгарыла. Хезмәтнең төп эчтәлеге, куелган максат һәм бурычларга туры килү-килмәве, яклауга чыгарылган положениеләр ни дәрәҗәдә хәл ителгән, шуларга бәя бирү рәвешендә булырга тиеш.

Йомгакта гомуми нәтиҗәләр генә бирелә һәм аның аша хезмәтнең эчтәлеге аңлашылып торырга тиеш.

Йомгак һәр параграф яисә бүлек азагында китерелгән нәтиҗәләрнең сүзгә сүз бирелеше булырга тиеш түгел. Анда яңа нәтиҗәләр, тулаем эшкә бәя бирә алырлык гомумиләштерелгән фикерләр булырга тиеш. Шулай ук йомгакта төп өлештә каралмаган яңа мәгълүматлар, карашлар, теоретик уйланулар булырга тиеш түгел; цитаталар, астөшермәләр, башка әдәбиятка таяну шулай ук булырга тиеш түгел. Курс эше йомгагының күләме тулы 2 бит, чыгарылыш квалификация эшенең йомгагы тулы 3 биттән ким булмаска тиеш.

## 2.6. Библиография.

Хезмәтне язу процессында файдаланылган хезмәтләр: монографияләр, дәреслекләр, җыентыклар, конференция материаллары һ.б. чагылыш таба. Фәнни эшнең библиографиясе ике өлештән тора:

1. Чыганаклар. Монда фактик материал алынган матур әдәбият исемлеге, төрле сүзлекләр (аңлатма яисә билгеләмәләр түгел, нәкъ менә мисаллар чыганагы буларак), диалектологик материаллар һ.б. булырга мөмкин.

2. Фәнни әдәбият исемлеге. Рус яисә татар телендә булуына карап, шулай ук икегә бүлеп бирергә мөмкин. Әдәбият исемлеге, фәнни эшнең күләменә карап, андагы бит санынннан ким булмаска тиеш, ягъни эшнең күләме 50 бит булса, библиографиядә 50 һәм артыграк хезмәт китерелергә

тиеш. Библиографияне төзү тәртибе һәм аңа куелган таләпләрне методик кулланмабызның ахырында китерелгән кушымталарга карап аңлап була.

## 2.7. Кушымта.

Кушымтада эшнең төп нәтиҗәләрен чагылдырган таблицалар, диаграммалар, схемалар, сүзлекчәләр, җыелган фактик материаллар, әдәби текстларның күчерелмәләре һ.б. бирелергә мөмкин. Әгәр эштә берничә кушымта урнаштырылса, алар номерлана, кайвакыт исемләнәләр.

Хезмәттә автор кыскартылмалары кулланылса, библиографиядән соң шартлы кыскартылмалар исемлеге урнаштырыла.

## III. КУРСҺӘМ ЧЫГАРЫЛЫШ КВАЛИФИКАЦИЯ ЭШЛӘРЕНДӘ МАТЕРИАЛЛАРНЫҢ БИРЕЛЕШЕНӘ ТАЛӘПЛӘР

### 3.1. Гомуми таләпләр.

Фәнни эш түбәндәге төп таләпләргә җавап бирергә тиеш:

1. Эш компьютерда җыела, A4 форматындагы бертөрле ак кәгазьнең бер ягына гына бастырыла. Бер биттә уртача 28-30 юл, ә һәр юлда сүз һәм тыныш билгеләреннән соң калдырылган буш араларны исәпләп, 60-65 билге булырга тиеш.

2. Текст Times New Roman шрифтында, 14 кегль белән, юллар арасы (интервал) 1,5 булырга тиеш.

3. Һәр биттә сул яктан 3 см, өстән һәм астан – 2 см, уңнан – 1,5 см ара калдырыла. Кызыл юл 1,25 см тәшкил итә.

4. Битләр саны өстә, бит уртасында куела. Титул һәм эчтәлек битләрендә бит саны күрсәтелми. Нумерация керештән һәм 3 биттән башлана.

5. Төп эштә сүзләрнең татар орфографиясе һәм пунктуациясе кагыйдәләре тарафыннан кабул ителгән кыскартылмалардан тыш, башка сүзләрне кыскарту кабул ителми.

6. Текстның басма вариантларында икенче ягында өстәмә текстлар, таблицалар һ.б. китерү катгый тыела. Шулай ук тулаем абзацларны *«дәвамы фәлән биттә»* дип күчерү таләпләргә туры килми.

7. Фәнни эшнең титул бите кафедра һәм факультет деканаты тарафыннан расланган үрнәк буенча языла, бүлекләр тәртип буенча номерлана һәм рим саннары, ә параграфлар гарәп саннары белән бирелә. Кереш, йомгак, кушымталарга тәртип саны куелмый. Шулай ук аларның һәм бүлекләрнең исемнәре баш хәрефләрдән языла. Параграфларның атамалары юл хәрефләре белән бирелә (Эчтәлек үрнәге кушымтада китерелә).

Төп өлештә һәр бүлек яңа биттән башлана. Бүлек эчендәге параграфлар бер-бер артлы дәвам иттерелә. Әгәр киләсе параграфның биткә бары тик исеме яки исеме белән бер-ике юлы гына сыйса, аны яңа биткә күчерәләр.

### 3.2. Сылтамалар яки астөшермәләрнең бирелеше.

Фәнни эшләрдә галимнәрнең, тел яисә әдәбият белгечләренең тикшерелә торган мәсьәләгә карашларын, төрле фикерләрен китермичә мөмкин түгел. Аларны тулаем текст өзеге итеп, ягъни цитата итеп бирергә була яки бу фикерләр язылган хезмәтләргә ишарә генә ясарга мөмкин. Бу ишарәләрне башкача *сылтама* яки *астөшермә* дип атыйлар. Сылтамаларны текстта ике төрле бирергә мөмкин: текст эчендә һәм бит ахырында (астөшермәләр). Тик эшнең башыннан азагына кадәр боларның бары бер варианты гына кулланылырга тиеш.

Астөшермәләр, алда әйтелгәнчә, бит азагында бирелә. Нумерация һәр биттә яңача башланырга  яки фәнни-тикшеренү эшенең башында 1 номердан башланып, эш азагына кадәр N номерына кадәр дәвам иттерелергә мөмкин. Җөмлә азагында махсус астөшермә номеры куела, шулай эшләгән очракта гына, бит азагында хезмәтнең библиографик чыганакларын күрсәтү өчен юл барлыкка киләчәк. Моның өчен Word документының өстә урнашкан эш панелендә «Вставка», «Ссылка», «Сноска», «В конце страницы» дигән параметрларын сайларга кирәк.

Астөшермәләрдә хезмәт турында тулы мәгълүмат китерелә: авторы, исеме, чыккан урыны, нәшрияты, елы һәм текстның кайсы битләрдән алынганы.

Әгәр бер биттә бер үк хезмәткә рәттән ике яки өч тапкыр таянырга туры килсә, «Шунда ук» дип кенә языла. Бите үзгәрсә, «Шунда ук. – Б.35» дип битен дә күрсәтергә кирәк. Түбәндә астөшермәләрнең бирелеше үрнәк итеп бирелә:

[1] Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. – Казан: Мәгариф, 1994. – Б. 112.

[2] Шунда ук. – Б.15.

[3] Шунда ук.

Текст эчендә китерелә торган сылтамалар төрлечә бирелергә мөмкин.

Кафедра утырышында, эшләрдә төрлелек булмасын өчен, бары бер вариант сайлап алына һәм студентлар тарафыннан бары шул кабул ителгән сылтамалар кулланыла.

1. Библиографиядә күрсәтелгән хезмәтләр номерланган булса, квадрат җәяләр эчендә аның номеры һәм өтердән соң кайсы биттәге текст файдаланылганы күрсәтелә. Мәсәлән, [25, Б.302].

Башкача да бирергә ярый: авторның фамилиясе, китапның чыккан елы һәм бите бирелә. Мәсәлән, [Сәлимов 2002: 25] яки [Сәлимов, 2002, Б.25].

Бер үк фамилияле авторлар берничә булса, сылтамада аның инициаллары да чагылыш табарга тиеш: [Сафиуллина Ф.С., 1999, Б.202].

Китапның авторы берничә булганда, ул түбәндәгечә күрсәтелә: [Сафиуллина, Фаткулова, 2002, Б.202-204].

Хезмәтнең авторы булмаса, китап исеменең беренче ике сүзе бирелә, алардан соң күпнокталар куела, өтерләрдән соң чыккан елы, бите күрсәтелә. Күпнокталар алдыннан һәм артыннан бер буш урын (пробел) куела: [Хәзерге татар ... , 1965, Б.202].

Бер үк вакытта берничә хезмәткә таянганда, хезмәтләрне күрсәткән төркемнәр арасына нокталы өтер куела: [25, Б.32; 36, Б.45; 56, Б.6] яки [Сафиуллина, 1974, Б.32; Галләмов, 2006, Б.189-191].

Әгәр бер хезмәткә эзлекле рәвештә ике яки өч тапкыр таянырга туры килсә, [Шунда ук] дип кенә языла. Бите үзгәрсә, [Шунда ук. Б.35] дип битен дә күрсәтергә кирәк.

Еш кына интеренет ресурслардан да файдаланырга туры килә. Мондый очракларда сылтама интернет ссылка ярдәмендә күрсәтелә. Шунысы мөһим: бу адреска мөрәҗәгать итү датасы җәяләр эчендә күрсәтелергә тиеш. Мәсәлән, http//www.belem.ru (чыгу вакыты: 13.02.2013).

### 3.3. Таблицалар.

Цифрларга нигезләнгән материал таблицалар ярдәмендә бирелә ала. Алар текст эчендә яки кушымтада урнаштырылырга мөмкин. Текстта

таблицаларны укырга уңайлы булган рәвештә, вертикаль яки сәгать йөреше буенча борып, урнаштыралар.

Юллары күп булган таблицаны алдагы биткә күчерергә рөхсәт ителә. Бу очракта, аның исеме таблица алдыннан урнаштырыла, ә алдагы биттә *Табл. дәвамы* дип язып куялар. Әгәр эштә берничә таблица урнаштырылса, аны икенче биткә күчергәндә, *1 табл. дәвамы* дип аның номерын да күрсәтергә кирәк була. Һәр таблица исемләнгән булырга тиеш, аның алдыннан битнең уң ягында, гарәп саннары белән номерын күрсәтеп, *Таблица* сүзе языла. Эштә таблица бердән бер булса, аны номерлау кирәк түгел.

Фәнни-тикшеренү эшенең текстында әлеге таблицаларның номерын күрсәтеп, ишарәләр булырга тиеш. Мәсәлән, «фикерләрне 1 таблицада урнаштырылган саннар дәлилли».

### 3.4. Иллюстрацияләр (рәсемнәр).

Иллюстрацияләр (схемалар, рәсемнәр, диаграммалар, фотографияләр) *Рәс.* дигән тамга белән бирелә. Алар, таблицалар кебек үк, текст эчендә яки кушымтада китерелә алалар. Еш кына рәсем астында аңлатмалар да булырга мөмкин. Иллюстрациянең исемен нәкъ аның өстендә, аңлатмаларын – астында, аңлатмалардан соң гына номеры куела.

Курс яки чыгарылыш квалификация эше текстында *1 рәс. кара* дигән ишарәләр булырга тиеш.

### 3.5. Кушымталар.

Кушымталарда ярдәмче материаллар (рәсемнәр, схемалар, графиклар, сүзлекчәләр һ.б.) урнаштырыла. Һәр кушымта яңа биттән, өске уң якта КУШЫМТА сүзеннән башланырга тиеш. Әгәр кушымталар берничә булса, алар номерланалар, мәсәлән, КУШЫМТА 1, КУШЫМТА 2 һ.б.

Һәр кушымтаның исеме булырга һәм ул КУШЫМТА сүзеннән соң битнең уртасында язылырга тиеш.

Фәнни эшнең дәвамы буларак, кушымтада битләр саны дәвам иттерелә, ул библиографиядән соң китерелә.

Текстта кушымтага ишарә ясаганда, түгәрәк җәяләр эчендә аның номерын күрсәтеп, танышырга тәкъдим ителә. Мәсәлән, (*Кара: Кушымта 1)*.

## 3.6. Библиография

Библиографиядә бары курс яки чыгарылыш квалификация эшен язганда реаль кулланылган чыганаклар һәм әдәбият исемлеге китерелергә тиеш.

Чыганаклар һәм әдәбият исемлеге аерым исемлекләр булып бирелә.

Чыганакларда тикшерү материалы буларак кулланылган матур әдәбият әсәрләре, җыентыклары, газета-журналлар, шәхси хатлар, истәлекләр, архив материаллары (борынгы язмалар күчерелмәләре) һ.б. күрсәтелә. Чыганаклар алфавит тәртибендә урнаштырылалар.

Әдәбият исемлегендә төрле монографик хезмәтләр, тикшерелә торган мәсьәлә буенча төрле мәкаләләр тупланган газета-журналлар, белешмәләр, сүзлек һәм энциклопедияләр, авторефератлар һәм диссертацияләр күрсәтелергә тиеш.

Хезмәтләр алфавит тәртибендә, башта татар телендә, аннары рус, алардан соң чит телләрдә басылганнары урнаштырыла.

Чыганаклар һәм әдәбият исемлеген түбәндәгечә бирергә мөмкин:

БИБЛИОГРАФИЯ

I. Чыганаклар.

1.1. ...

1.2. ... (һ.б.)

II. Әдәбият исемлеге.

2.1. ...

2.2. ... (һ.б.)

Югарыдан күренгәнчә, чыганаклардан соң китерелгән әдәбият исемлегендә нумерация яңадан башлана.

Китапның библиографик тасвирламасының схемасы түбәндәгеләрне чагылдырырга тиеш:

Авторның фамилиясе һәм инициаллары. Титул битендә күрсәтелгән китап исеме. – Нәшер ителү урыны: нәшрият исеме яки нәшер итүче оешма, нәшер итлү елы. – Күләме (битләр саны). Мәсәлән:

Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.

Авторлар саны 2-3 булса, фамилияләрне өтер аша күрсәтәләр. Мәсәлән: Заһидуллина Д.Ф., Әминева В.Р., Закирҗанов Ә.М. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

Авторлар саны өчтән артып китсә, беренче авторның фамилиясе һәм инициаллары күрсәтелгәннән соң *һәм башкалар* дип языла.

Кайчакта хезмәтнең авторы күрсәтелми, бары редакторы, төзүчесе яисә бу хезмәт өстендә эшләгән шәхесләр төркеме бирелә. Бу очракта библиографик тасвирламаны болай бирү дөрес булыр: Диалектологик сүзлек (Татар диалектларын өйрәнү юлында беренче тәҗрибә). Өченче чыгарылыш. / Төз.: Борханова Н.Б., Махмутова Л.Т. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1953. –260 б.

Хезмәт берничә томны тәшкил иткән очракның библиографик тасвирламасы: Китапның исеме: томнарның гомуми саны / Басма өчен җаваплылар. – Нәшер итү урыны: нәшрият исеме, беренче һәм соңгы томнарның нәшер ителү еллары. Мәсәлән:

Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда / Төз. Н.Исәнбәт. − Казан: Тат.кит.нәшр., 1989-1990.

Күптомлы басманың бер томы гына кулланылса:

Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. − Казан: Тат.кит.нәшр., 1990. − Т.2. − 365 б.

*Хезмәтләрнең библиографик тасвирламаларын үрнәк өчен кушымтада тәкъдим итәбез.*

# IV. КУРС ҺӘМ ЧЫГАРЫЛЫШ КВАЛИФИКАЦИЯ ЭШЛӘРЕН ЯКЛАУ

## 4.1. Чыгарылыш квалификация эшен яклауга әзерлек

Студент чыгарылыш квалификация эшен язу һәм яклау календарь планында күрсәтелгән вакытка фәнни җитәкчегә тапшырырга тиеш. Җитәкче эшне тулысынча тикшереп, аның куелган таләпләргә туры килү-килмәвен билгеләп, эшнең эшләнеп бетү дәрәҗәсен билгели. ДАК утырышына 3 атна кала, чыгаручы кафедрада якынча яклау (предзащита) үткәрелә. Монда бары тулысынча яклауга әзер эшләр генә кабул ителә.

Алдан яклап карау нәтиҗәләре буенча, кафедра мөдире һәм фәнни җитәкче эшнең ДАК утырышында яклауга кертелү-кертелмәве турында карар кабул итәргә тиешләр. Уңай бәяләнсә, фәнни эшне рецензентка тапшырырга рөхсәт ителә.

ЧКЭ яклауга, уңай яки тискәре булуына карамастан, бары рецензентның бәяләмәсе булган очракта гына кертелә. Яклауга бер көн кала, тышлыкка төпләнгән чыгарылыш квалификация эше, фәнни җитәкченең һәм рецензентның бәяләмәләре ДАК сәркәтибенә тапшырылырга тиеш.

Билгеләнгән вакытка эш кафедрага тапшырылмаса, куелган таләпләргә туры килмасә, яки фәнни җитәкче тарафыннан эш начар бәяләнсә, кафедра карары нигезендә ул яклауга кертелмәскә мөмкин.

Чыгарылыш квалификация эшен яклау алдыннан чыгышның текстын, презентациясен эзерләп кую кирәк. Анда үткәрелгән тикшерүләрнең төп идеяләре, нәтиҗәләре, авторның бу идеяне тикшерүгә керткән өлеше, актуальлеге, максат һәм бурычлары, фәнни яңалыгы, практик әһәмияте күрсәтелергә тиеш. Чыгыш тексты тыңлау өчен аңлаешлы, эзлекле итеп төзелергә, фикерләрне раслаучы презентациядәге слайдларга урынлы мөрәҗәгать итү булырга тиеш. Чыгыш вакыты чамалап 5 минут, яисә 5 битлек тексттан арттырмауны онытмаска кирәк.

## 4.2. Курс яки чыгарылыш квалификация эшен яклау

### *Чыгарылыш квалификация эшен яклау*

Чыгарылыш квалификация эшен яклау уку процессының мөһим һәм соңгы этабы булып санала. Уку планын тулысынча үтәгән, ЧКЭны вакытында, бар таләпләргә туры китереп тапшырган, фәнни җитәкченең һәм рецензентларның бәяләмәләре булган очракта гына студентлар яклауга кертелә.

Чыгарылыш квалификация эшен яклау ДАКның ачык утырышында үткәрелә. Анда ДАК рәисе һәм әгъзалары, фәнни җитәкчеләр, рецензентлар, чыгарылыш квалификация эшләрен яклаучылар һәм теләгән студентлар катнаша ала.

Сүз яклаучыга бирелгәннән соң, ул әзерләгән чыгышын тыңлаучыларга тәкъдим итә. Ул билгеләнгән регламент эчендә эшенең кыскача эчтәлеге, теманың актальлеге, теоретик һәм гамәли әһәмияте, кулланылган эш метод һәм алымнары, төп нәтиҗәләре белән таныштыра.

ЧКЭда схемалар, диаграммалар, таблицалар һ.б. китерелгән булса, яклау процессында алардан да файдалана ала. Болар, үз чиратында, нәтиҗәләрнең дөреслегендә шик калдырмаячак, аларның далилле, ныклы булуын күрсәтә, тыңлаучыларга чыгышны кабул итүне җиңеләйтә.

Чыгышы тәмамлангач, яклаучыга шул тема буенча сораулар бирелә. Аларга кыска һәм төгәл, аңлаешлы җаваплар бирелергә тиеш. Шуннан соң эшкә бәя бирү өчен, сүз рецензентка бирелә. Җитәкче һәм рецензент күрсәткән кимчелекләренә, сорауларына җавап бирү һәм теге яки бу мәсьәләгә үз мөнәсәбәтен белдерү өчен, яклаучыга кабат сүз бирелә, ДАК рәисе һәм әгъзаларына, фәнни җитәкчегә һәм рецензентка, яклауда катнашучыларга үзенең рәхмәтен белдерә.

Чыгарылыш квалификация эшен яклаучы үзе сайлаган белгечлек буенча теоретик белеменең тирәнлеген күрсәтергә, алган белемнәрен конкрет гамәли мәсьәләне чишкәндә кулана белергә, фәнни-тикшеренү эшләренең методикасын яхшы төшенгән булырга, дөрес итеп материалны бирә белергә,

төп нәтиҗәләрне нигезли алырга тиеш. Болар барысы да билге куйганда исәпкә алына.

Чыгарылыш квалификация эшенә билге кую, аны бәяләү фәнни җитәкченең бәяләмәсеннән башланырга тиеш. Ул һәрбер бүлекнең эчтәлегенә бәя бирә, студентларның ни дәрәҗәдә мөстәкыйль фикер йөртүен, иҗади эшләвен билгели, эшнең төп нәтиҗәләрен гамәли куллану буенча үзенең тәкъдимнәрен әйтә, эшкә караган гомуми кимчелекләрне күрсәтә, якынча билгене тәкъдим итә.

Рецензент бәяләмәсе ДАК өчен бик әһәмиятле документ булып санала. Анда чыгарылыш квалификация эше эчтәлегенең темага туры килүе, теманың актуальлеге һәм әһәмияте, төп нәтиҗәләргә бәя, энең гамәли әһәмияте, төп кимчелекләр һәм бәхәсле урыннар, тәкъдим ителә торган билге һ.б. чагылыш табарга тиеш.

ДАК әгъзалары студентның эшен бәялиләр һәм билге куялар. Ул «канәгатьләнмәслек» (икеле), «канәгатьләнерлек» (өчле), «яхшы» (дүртле), «бик яхшы» (бишле) билгесе булырга мөмкин. Нинди билге кую турындагы карар ачык рәвештә тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Шулай итеп, билге рецензент һәм җитәкче бәяләмәләре, яклаучының чыгышын һәм сорауларга җавабын исәпкә алып куела. Ул ДАКның ябык утырышында кабул ителә һәм беркетмәгә теркәлеп куела. Билге куйганда, бәхәс чыгып, тавышлар тигез булса, ДАК рәисенең фикере соңгысы һәм хәлиткеч була. Бар билгеләр куелып беткәч, чыгарылыш квалификация эшләре яклаучылар кабат чакырыла һәм аларга куелган билгеләр игълан ителә. Әгәр ЧКЭ «канәгатьләнмәслек» (икеле) билгесенә бәяләнсә, аны яңадан яклау вакыты билгеләнә.

*Курс эшләрен яклау*

Курс эшләрен яклау гадиләштерелгән варианта үтә. Аларны өчтән дә ким булмаган комиссия алдында яклыйлар. Комиссиягә җитәкче, кафедра мөгаллиме һәм шул фән буенча кафедра тарафыннан билгеләнгән рәис керә. Яклауда бу өлкәдә курс эшләре язган һәм якларга әзер булган бар студентлар

катнаша.

Курс эше материаллары белән таныштырыр өчен студентка 5-7 минут вакыт бирелә. Чыгыштан соң, студентка эше буенча комиссия әгъзалары, башка студентлар сораулар бирә. Сорауларга җавап бирелгәч, фәнни җитәкче телдән үзенең бәяләмәсен бирә, үз фикерләрен комиссия әгъзалары да белдерә. Ахырда чыгыш ясаган студентка яңадан сүз бирелә.

Курс эшләре барысы да якланып беткәч, комиссия әгъзалары киңашләшеп, билгеләр куялар. Курс эшенә билге куйганда аның бу төр эшләргә куелган таләпләргә туры килүе, сорауларга җаваплар, фәнни җитәкченең бәяләмәсе исәпкә алына.

ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

1. Татар теленнән язма эшләр: студентлар өчен методик кулланма / Төз. Х.Х. Сәлимов. – Алабуга, 1998. – 22 б.

2. Туган тел һәм әдәбият белгечлеге буенча курс һәм чыгарылыш квалификация эшләре: студентлар өчен методик кулланма / Төз. Р.Х. Мөхиярова. – Казан: Школа, 2008. – 28 б.

3. Положение о курсовой работе студентов // Сборник нормативных документов Елабужского государственного педагогического университета (Утвержден Ученым советом ЕГПУ протокол №1 от 27.09.2007 г.). – Елабуга: Изд-во ЕГПУ, 2008. – С. 139-145.

4. Положение о выпускной квалификационной работе студентов // Сборник нормативных документов Елабужского государственного педагогического университета (Утвержден Ученым советом ЕГПУ протокол №1 от 27.09.2007 г.). – Елабуга: Изд-во ЕГПУ, 2008. – С. 146-158.

5. Положение об итоговой государственной аттестации выпускников // Сборник нормативных документов Елабужского государственного педагогического университета (Утвержден Ученым советом ЕГПУ протокол №1 от 27.09.2007 г.). – Елабуга: Изд-во ЕГПУ, 2008. – С. 133-139.

6. Библиографическая ссылка. Общие требования и правила составления: издание официальное. – М.: Стандартинформ, 2008. URL: http://protect.gost.ru/document (дата обращения: 05.10.2008).

КУШЫМТА 1

Чыгарылыш квалификация эшен язу һәм яклау графигы

| № | Эш этаплары | Үтәлү вакыты |
|---|---|---|
| 1. | Теманы раслау һәм фәнни җитәкчене билгеләү | сентябрь |
| 2. | Индивидуаль план буенча эшләү | Уку елы дәвамында |
| 3. | Фәнни-тикшеренү эшенең каралама вариантын фәнни җитәкчегә тапшыру | Дәүләт имтиханнарына чаклы 8 атна алдан |
| 4. | Чыгаручы кафедра каршында яклап карау | Дәүләт имтиханнарына чаклы 3 атна алдан |
| 5. | Төзәтелгән чыгарылыш квалификация эшенә бәяләмә һәм рецензия язу өчен чыгаручы кафедрага тапшыру | Яклауга чаклы 10 көн алдан |
| 6. | Эшнең яклауга әзер экземплярын җитәкче бәяләмәсе һәм оппонент рецензиясе белән чыгаручы кафедрага тапшыру | Яклауга чаклы 3 көн алдан |

Чыгарылыш квалификация эшен язучы студент имза И.О. Фамилия

Фәнни җитәкче имза И.О. Фамилия

КУШЫМТА 2

*Курс эшенең титул бите*

Россия федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгы

Югары белем бирүче федераль  дәүләт үзидарәле мәгариф учреждениесе
″Казан (Идел буе) федераль университеты″

Югары белем бирүче федераль  дәүләт үзидарәле мәгариф учреждениесе
″Казан (Идел буе) федераль университеты″ның
Алабуга институты

ТАТАР ҺӘМ ЧАГЫШТЫРМА ФИЛОЛОГИЯ ФАКУЛЬТЕТЫ

ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ КАФЕДРАСЫ

Белгечлек № 050302.65 – Чит тел өстәмә белгечлеге белән татар теле һәм әдәбияты

КУРС ЭШЕ

**Т.МИҢНУЛЛИН ИҖАТЫНДА**

**ЭМОЦИОНАЛЬ-ЭКСПРЕССИВ ЛЕКСИКА**

Фәнни эшне башкарды:
татар һәм чагыштырма
филология факультетының
IV курс е045 төркем студенты
Закирова А.Ш.

Фәнни җитәкче:
филология фәннәре кандидаты,
доцент Ф.И. Габидуллина

Алабуга – 2013

КУШЫМТА 3

*Титул битенең татарча варианты үрнәге*

Россия федерациясе мәгариф һәм фән министрлыгы

Югары белем бирүче федераль дәүләт үзидарәле мәгариф учреждениесе
″Казан (Идел буе) федераль университеты″

Югары белем бирүче федераль дәүләт үзидарәле мәгариф учреждениесе
″Казан (Идел буе) федераль университеты″ның
Алабуга институты

ТАТАР ҺӘМ ЧАГЫШТЫРМА ФИЛОЛОГИЯ ФАКУЛЬТЕТЫ

ТАТАР ФИЛОЛОГИЯСЕ КАФЕДРАСЫ

Белгечлек № 050302.65 – Чит тел өстәмә белгечлеге белән татар теле һәм әдәбияты

ЧЫГАРЫЛЫШ КВАЛИФИКАЦИЯ ЭШЕ

**Ә.ЕНИКИ ИҖАТЫНДА ЯЛГЫЗЛЫК МОТИВЫ**

**Эш төгәлләнде:**
“___” __________2012 ел ______________________(А.З. Гәйнетдинова)

**Эш яклауга әзер:**
Фәнни җитәкче
филология фәннәре кандидаты,
доцент
“___” __________2012 ел ______________________(Ф.И. Габидуллина)

Кафедра мөдире
филология фәннәре кандидаты,
доцент

“__” _______2012 ел _____________________________(Г.Ф. Даутов)

**Алабуга – 2012**

КУШЫМТА 4

*Титул битенең русча варианты үрнәге*

Министерство образования и науки РФ

Федеральное государственное автономное образовательное
учреждение высшего образования
«Казанский (Приволжский) федеральный университет»

Елабужский институт Федерального государственного автономного
образовательного учреждения высшего образования
«Казанский (Приволжский) федеральный университет»

ФАКУЛЬТЕТ ТАТАРСКОЙ И СОПОСТАВИТЕЛЬНОЙ ФИЛОЛОГИИ

КАФЕДРА ТАТАРСКОЙ ФИЛОЛОГИИ

Специальность № 050302.65 – Родной язык и литература с дополнительной специальностью иностранный язык

ВЫПУСКНАЯ КВАЛИФИКАЦИОННАЯ РАБОТА

**МОТИВ ОДИНОЧЕСТВА В ТВОРЧЕСТВЕ А.ЕНИКИ**

**Работа завершена:**

"___"_________ 20_ г. ____________________ (А.З. Гайнутдинова)

**Работа допущена к защите:**

Научный руководитель
кандидат филологических
наук, доцент
"___"_________ 20_ г. ____________________ (Ф.И. Габидуллина)

Заведующий кафедрой
кандидат филологических
наук, доцент

"___"_________ 20_ г. ____________________ (Г.Ф. Даутов)

**Елабуга – 2012**

КУШЫМТА 5

*Курс яки чыгарылыш квалификация эше эчтәлеге үрнәге*

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ..........................................................................................................3

БҮЛЕК I. КҮЧЕРЕЛМӘ МӘГЪНӘ БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШЛЕ СТИЛИСТИК АЛЫМНАРНЫҢ ПЕЙЗАЖ ТУДЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ................................6

1.1. Метафора..................................................................................................9

1.2. Чагыштыру..............................................................................................13

1.3. Сынландыру............................................................................................16

1.4. Эпитет......................................................................................................20

БҮЛЕК II. ПЕЙЗАЖ ТУДЫРУДА ЛЕКСИК ЧАРАЛАРНЫҢ РОЛЕ (Н.ГЫЙМАТДИНОВАНЫҢ “СӘВИЛӘ”, “БОЛАН”, “УТ КҮБӘЛӘГЕ” ӘСӘРЛӘРЕ МИСАЛЫНДА)........................................................................25

2.1. Синонимнар............................................................................................28

2.2. Антонимнар.............................................................................................29

2.3. Фразеологизмнар....................................................................................30

БҮЛЕК III. Н.ГЫЙМАТДИНОВА ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ПЕЙЗАЖ ТУДЫРУДА КАБАТЛАУЛАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ.........................38

3.1. Анафора...................................................................................................45

3.2. Эпифора...................................................................................................46

ЙОМГАК......................................................................................................46

БИБЛИОГРАФИЯ……………................................................................52

КУШЫМТА..................................................................................................55

КУШЫМТА 6

## Хезмәтләрнең библиографик тасвирламасы

### *Бер авторлы хезмәтләр*

Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 176 б.

Бәширова И.Б. Хәзерге татар әдәби теле. Семасиология: Татар лексикасында системалы бәйләнеш-мөнәсәбәтләр. – Казан: Алма-Лит, 2006. – 196 б.

Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау. – Казан: Мәгариф, 2005. – 95 б.

Курбатов Х.Р. Сүз сәнгате. Татар теленең лингвистик стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.

### *Ике-өч авторлы хезмәтләр*

Вәлиуллина З.М., Зиннәтуллина К.З., Сәгыйтов М.А. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. – Казан: КДПИ, 1972. – 206 б.

Ибраһимов С.М., Сафиуллина Ф.С. Практик стилистика: күнегүләр җыентыгы. – Казан: Тат. кит. нәшр.,1978. – 144 б.

Заһидуллина Д.Ф., Әминева В.Р., Закирҗанов Ә.М. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

Сафиуллина Ф.С., Сәлимов Х.Х., Сәлимова Д.А. Тел гыйлеменә кереш. − Казан: Казан ун-ты нәшр., 2000. − 126 б.

### *Дүрт һәм аннан артык авторлы китаплар*

Основы теории коммуникации: учебник / Под ред. М.А. Василика. – М.: Гардарикн, 2006. – 615 с.

*Күптомлы яисә берничә кисәктән торган китапларның аерым томнарын бирү*

Барт Р. Лингвистика текста // Новое в зарубежной лингвистике. М.: Прогресс, 1978. – Вып. 8: Лингвистика текста. – С.442-449.

Закиев М.З., Сафиуллина Ф.С. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Простое предложение: в 3 ч. – Казань: КГПИ, 1977. – Ч.1. – 87 с.

Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. − Казан: Тат.кит.нәшр., 1990. − Т.2. − 365 б.

Словарь синонимов русского языка: В 2-х томах / Под ред. А.П. Евгеньевой. − Л.: Наука, 1970. − Т.1. − 400 с.

*Газета-журналларда басылган мәкаләләр*

Әхмәтҗан Р. Шигъриятнең триумфаль капкасы. Х.Туфан // Ватаным Татарстан. − 2002. − 11 октябрь. − Б.11.

Мифтахова М.А. Х.Туфан иҗатын өйрәнү // Мәгариф. − 2003. − №11. − Б. 9-11.

Мөхәммәтдинова Р. Зур хисләр һәм тирән идеяләр шагыйре: Х.Туфан // Алабуга нуры. − 2000. − №7. − Б.3.

Хисаметдинова Р. Шигърияттә халык язмышы // Мәгариф. − 1995. − №3. – Б. 23-25.

*Җыентыкларда басылган мәкаләләр*

Галләмов Ф.Г., Әдһәмова Р.Ә. Татар телендә мөрәҗәгать җөмләләр // Татар филологиясе мәсьәләләре. – Алабуга: АДПУ нәшр., 2001. – Б. 45-49.

Лаисов Н. Шагыйрь турында тәнкыйть // Хәсән Туфан: Шагыйрьнең иҗат юлы турында / Төз. Т.Галиуллин. − Казан: Тат.кит.нәшр., 1976. − Б. 98-124.

*Авторы күрсәтелмәгән китапларны бирү тәртибе*

Татарский энциклопедичекий словарь / Гл. ред. М.Х. Хасанов. − Казань: Интитут Татарской энциклопедии АН РТ, 1999. − 703 с.

Татарча-русча фразеологик сүзлек / Төз. Ф.С. Сафиуллина. − Казан: Мәгариф, 2001. − 335 б.

Хәзерге татар әдәби теле: югары уку йортлары өчен дәреслек / җаваплы ред. Х.Курбатов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1965. – 300 б.

*Авторефератлар һәм диссертацияләрдән алынган материалларны күрсәтү*

Ахунзянов Г.Х. О стилистических особенностях образных фразеологических выражений: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Казань, 1964. − 25 с.

Галлямов Ф.Г. Лексқио-грамматические особенности повторов в современном татарском языке: дис. ... докт. филол. наук. – Уфа, 2007. – 398 с.

Гилязева Э.Н. Лингвокультурологические особенности фразеологических единиц с компонентом «предметы быта» в татарском и немецком языках: автореф. дисс. … канд. филол. наук. − Казань, 2006. − 30 с.